КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 17 ноябрь г.Казань № 1100

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында санитария-эпидемиология хәлен һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 28 октябрь, 1006 нчы; 2021 ел, 29 октябрь, 1018 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе территориясендә 2021 елның октябрендә – ноябрендә эш көне булмаган көннәрне билгеләү турында» 2021 елның 20 октябрендәге 595 номерлы Указы,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта:

беренче абзацта «санитария-эпидемиология хәле яхшырганга кадәр» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацта «санитария-эпидемиология хәле яхшырганга кадәр» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «санитария-эпидемиология хәле яхшырганга кадәр» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «санитария-эпидемиология хәле яхшырганга кадәр» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктта:

унөченче абзацта «затлар» сүзен «булучылар» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2021 елның 15 ноябреннән 18 яшьтән өлкәнрәк тамашачыларга, QR-кодларын күрсәтмичә, театрларга, кинотеатрларга (кинозалларга), циркларга, концерт залларына, тамашачылар катнашында үткәрелә торган рәсми физкультура, рәсми спорт, мәдәни чараларга керү һәм аларда булу;

2021 елның 22 ноябреннән, кемгә каравын раслап, QR-кодларын яки яңа коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) каршы вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләрен раслаган гамәлдәге шәхси QR-кодларын (алга таба – вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләре турында QR-код) күрсәтмичә, автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртүне һәм багажлар ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чараларында (җиңел такси һәм төбәкара маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багажлар ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чараларыннан башка), шәһәр җир өсте электр транспортында, метрополитенда 18 яшьтән өлкәнрәк пассажирлар юл йөрү, метрополитен станцияләренә 18 яшьтән өлкәнрәк пассажирлар керү һәм аларда булу;

2021 елның 22 ноябреннән автовокзалларда, автостанцияләрдә 18 яшьтән өлкәнрәк һәр пассажирга, алар QR-кодын яки вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләре турында QR-кодын күрсәтмичә, шәһәр яны һәм муниципальара элемтәләрнең даими йөртүләр маршрутларына билетлар сату.»;

6 пунктта:

«г» пунктчасында «(әлеге карарның 3 пунктындагы дүртенче абзацында каралган очрактан тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга;

«е» пунктчасында:

беренче абзацта «2021 елның 11 октябреннән 14 ноябренә кадәр» сүзләрен «2021 елның 15 ноябреннән» сүзләренә алмаштырырга, «500 кеше» сүзләрен «QR коды булган 500 кеше» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

«з» пунктчасында:

беренче абзацта «2021 елның 11 октябреннән 14 ноябренә кадәр» сүзләрен «2021 елның 15 ноябреннән» сүзләренә алмаштырырга , «500 кеше» сүзләрен «QR коды булган 500 кеше» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

8 һәм 9 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына медицина оешмалары тарафыннан яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләрен раслаган медицина бәяләмәләрендә (белешмә кәгазьләрендә) вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләре турында QR-кодларның булуын тәэмин итәргә.

9. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан

Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, юл йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы операторлары белән берлектә, түбәндәгеләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләгән тәртиптә тәэмин итәргә:

2021 елның 22 ноябреннән 60 яшьтән өлкәнрәк гражданнарга (түбәндәге гражданнардан тыш) карата ташламалы транспорт кушымталы электрон карталарның гамәлдә булуын туктатып торуны:

а) QR-кодларның булуы белән расланган яңа коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) каршы вакцинация ясаган яки соңгы алты айда әлеге авыру белән авырган;

б) вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләре турында QR-кодлар белән расланган яңа коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) каршы вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләре булган;

ташламалы транспорт кушымталы электрон карталарны туктатып тору нигезләре беткәннән соң, аларның гамәлдә булуын яңарту.»;

түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10. Гражданнарның 2021 елның декабре өчен бу карар нигезендә кулланууы туктатып торылган һәм 2021 елның декабрендә яңадан кулланыла башланмаган ташламалы транспорт кушымталы электрон карталарга салынган акчасы әлеге карталарга алар яңадан кулланыла башлаган айда күчерелә дип билгеләргә.»;

1 нче кушымтаның 2 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарында билгеләнгән чикләүләр срогы вакытында түбәндәгеләрне рөхсәт итмәскә:

«Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» (gosuslugi.ru) федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып алынган, коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) каршы вакцинация ясауны яки соңгы алты айда әлеге авыру белән авыру фактын раслый торган гамәлдәге шәхси QR-кодларын (алга таба – QR-код) күрсәтмичә, аларның кемнеке икәнен расламыйча, 18 яшьтән өлкәнрәк затларга җәмәгать туклануы хезмәтләре (җәмәгать туклануы объектлары урыннарына гражданнар кермичә алып чыгып биреп хезмәт күрсәтүдән, заказларны алып килеп бирүдән, аэропортлар, вокзаллар территорияләрендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүдән тыш), спорт үзәкләрендә, йөзү бассейннарында, фитнес-үзәкләрдә, аквапаркларда хезмәтләр күрсәтүне, 18 яшьтән өлкәнрәк затларның сәүдә, сәүдә-күңел ачу үзәкләренә (комплексларына), азык-төлек булмаган товарлар ваклап сатыла торган һәм килүчеләр өчен сәүдә залы 150 кв метрдан артык мәйданлы объектларга, җәмәгать туклануы объектлары урыннарына, 18 яшьтән өлкәнрәк тамашачыларның театрларга, кинотеатрларга (кинозалларга), циркларга, концерт залларына, тамашачылар катнашында үткәрелә торган рәсми физкультура, рәсми спорт, мәдәни чараларга керүен һәм аларда булуын;

балигъ булмаган затларның сәүдә, сәүдә-күңел ачу үзәкләренә (комплексларына) ата-аналары (законлы вәкилләре) озатуыннан башка керүе һәм аларда булуы;

кемгә каравын раслап, QR-кодларын яки яңа коронавирус йогышлы авыруына (COVID-19) каршы вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләрен раслаган гамәлдәге шәхси QR-кодларын (алга таба – вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләре турында QR-код) күрсәтмичә, автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртүне һәм багажлар ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чараларында (төбәкара маршрутлар һәм җиңел таксидан башка), шәһәр җир өсте электр транспортында, метрополитенда 18 яшьтән өлкәнрәк пассажирлар юл йөрү, метрополитен станцияләренә 18 яшьтән өлкәнрәк пассажирлар керү һәм аларда булу;

автовокзалларда, автостанцияләрдә 18 яшьтән өлкәнрәк һәр пассажирга, QR-кодын яки вакцинация ясарга ярамавын күрсәтә торган медицина билгеләре турында QR-кодын күрсәтмичә, шәһәр яны һәм муниципальара элемтәләрнең даими йөртүләр маршрутларына билетлар сату.».

2. Бу карар 2021 елның 22 ноябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин